ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Казан шәһәре № 5-116/тэ

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-91/тэ карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2020 елга җайга салынулы оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен үзгәрешләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 № 5-91/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-104/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-91/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-116/тэ карары редакциясендә)

## «Интергграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 574,15 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 590,15 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 528,47 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 530,26 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 530,26 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 560,64 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-91/тэ карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-116/тэ карары редакциясендә)

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2018-2020 елларга җайга салуның дәвамлы чорына билгеләнә торган җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата сарыфлар күләме | технологик сарыфлар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Казан шәһәре | | | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2018 | 31763,37 | 1 | 1,09 | 15432,0 |
| | | 2019 | Х | 1 | 1,09 | 15432,0 |
| | | 2020 | Х | 1 | 0,52 | 8743,8 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге